# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Арча районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Арча районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" 2011 елның 16 июнендәге 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Ватаным Татарстан, 2011, 18 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче суд участогы чиге тасвирламасының икенче абзацында "Носы, Иске Ашыт,", "Сөрде,", "Шурабаш," сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 нче суд участогы чиге тасвирламасының икенче абзацында "Венета, Казанбаш,", "Кушлавыч, Күпербаш,", "Сикертән, Курса-Почмак,", "Урта Пошалым,", "Өчиле," сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 12 декабре
№ 98-ТРЗ